СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2022 г.Зеленодольск № 210

Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль район Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.1.2 пунктында «тәэмин итү» сүзен «оешма» сүзенә алмаштырырга;
- 2.1.4 пунктында «һәм аларны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 2.1.6 пунктында «һәм җирле бюджетларның төп администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты чараларын гамәлгә ашыруны анализлау» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет

кодексының 269.2 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.1.10 пунктында «үз компетенциясе чикләрендә җирле бюджетлар башкара» сүзләрен «җирле бюджетларның үз компетенциясе кысаларында үтәлешен оештыра»; сүзләренә алмаштырырга;

- 3.1.14 пунктында «өлкәсендә» сүзен «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясы нигезе өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.1.15, 3.1.20, 3.1.21, 3.1.22 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

- түбәндәге эчтәлекле 3.1.32 пункт өстәргә:

«3.1.32. Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителә торган районның бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән җирле үзидарә финанс органының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

2.Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.П. Афанасьев**